«АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ»
№46 (405) | 26 ноябрь–2 декабрь 2021 ел
Республика яңалыклары –
www.tatar-inform.tatar сайтында

Кулланучы хәбәрләре

# Диагностика һәм экспертиза: аерма бар

## Хокукларны белү күңелсез хәлләрдән сакланырга ярдәм итә



**«Товарның диагностикасы нәрсәне аңлата, кибеттә товарны диагностика өчен берничә көнгә калдырып торырга тәкъдим иткән очракта нишләргә?**

**Игорь П.»**

«Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы Россия Федерациясе канунының 18 маддәсе 5 пункты нигезендә, әгәр товарның җитешсезлекләре ачыкланса, сатучы аның сыйфатын тикшерергә, ягъни диагностика ясарга бурычлы. Без исә диагностиканы күзәтергә хокуклы.

Әмма еш кына сатучылар товарны кибеттә калдырырга тәкъдим итә яки безне үзләренең сервис үзәкләренә җибәрә. Бу үзәкләргә, «эчке инструкция»ләргә таянып, безне кертмиләр, шул рәвешле, безне диагностика ясаганда законлы рәвештә катнашу хокукыннан мәхрүм итәләр.

Мондый хәл килеп чыга икән, ирекле формада язмача гариза язарга кирәк, анда товарның сыйфатын тикшерүне сезнең катнашыгыз белән уздыру турындагы таләп урын алырга тиеш, яки товарның экспертизасын мөстәкыйль рәвештә үз акчагызга ясаттыру хокукын үзегездә калдырасыз. Эксперт җитештерү характерындагы җитешсезлек барлыгын ачыкласа, сатучыдан товар өчен дә, экспертиза ясаткан өчен дә тотылган акчаларны кире кайтаруны таләп итәргә хакыгыз бар, чөнки болар – сез сыйфатсыз товар сатып алу белән бәйле рәвештә тоткан чыгымнар.

**Шул ук вакытта, диагностика белән бәйсез экспертиза арасындагы аерманы белергә кирәк: беренчесе сервис үзәкләрендә ясала, ә икенчесе аккредитацияләнгән эксперт оешмаларында тиешле вазифасы, белеме һәм әлеге эшчәнлектә мәгълүматы булган эксперт тарафыннан үткәрелә.**

# Гарантия вакыты чыкса

## Кулланучыга үз хокукларын яклау турында

**«Фатирымдагы тәрәзәләрне алыштырырга уйладым һәм пластик тәрәзә куйдырттым. Әмма җиде айдан аларның кимчелекләре ачыкланды. Тәрәзә куючыларга мөрәҗәгать иттем, тик ул гарантия вакыты чыкты инде, ди. Дөрестән дә, килешүдә гарантия вакыты алты ай дип язылган. Сатучыга үз таләпләремне белдерә аламмы?**

**Наталья П.»**




Әйе, чынлыкта Сез үз таләпләрегезне белдерергә хокуклы. «Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы Россия Федерациясе канунының 29нчы маддәсендә әйтелгәнчә, килешүдә күрсәтелгән гарантия вакыты ике елдан кимрәк булып, җитешсезлекләр кулланучы тарафыннан гарантия вакыты узганнан соң, әмма шул ике ел эчендә ачыкланса, кулланучы әлеге җитешсезлекләрнең ул әшне кабул итеп алганчы килеп чыкканлыгын, яки әлеге вакытка кадәр булган сәбәпләр аркасында барлыкка килүен дәлилли алса, кулланучының үз таләпләрен белдерергә хакы бар.

**Әгәр күрсәтелгән товарны бары тик аны сатып алган кеше генә кулланырга хокуклы булса, билгеле бер шәхси сыйфатларга ия товардан кулланучы баш тарта алмый.**

Иң беренче эш итеп, Сезгә сатучыга язмача шикаять белән мөрәҗәгать итәргә киңәш бирәбез. Канунда билгеләнгән вакыт эчендә тискәре җавап килсә, Сезнең законлы таләпләрегезне канәгатьләндерүдән баш тартсалар, кулланучы буларак хокукларыгызны яклау өчен ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә яки аның территориаль органнарына гариза белән мөрәҗәгать итә аласыз.